**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2602**
**03.04.2023**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 1625 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе турында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 1625 номерлы карары (Башкарма комитетның 2020 елның 22 октябрендәге 5445 номерлы карары редакциясендә) кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24-26 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

2) кушымтада каралганча 30-59 пунктлар өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2023 елның 3 апрелендәге
2602 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» яшьләр үзәге»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Чаралар үткәрү буенча хезмәтләр | | | |
| 30. | Кино күрсәтү – премьер зал | кеше/1 сәгать | 200,00 |
| 31. | Кино күрсәтү – конференц зал | кеше/1 сәгать | 120,00 |
| 32. | Иҗади чыгыш | кеше/1 сәгать | 300,00 |
| 33. | Иҗади оригиналь юнәлеш буенча мастер-класс | кеше/1 сәгать | 800,00 |
| 34. | Иҗади креатив юнәлеш буенча мастер-класс | кеше/1 сәгать | 1000,00 |
| 35. | Иҗади юнәлеш буенча мастер-класс | кеше/1 сәгать | 500,00 |
| 36. | Чараны утлар белән бизәү | 1 чара | 6000,00 |
| 37. | Чараны утлар белән бизәү | 1 сәгать | 1000,00 |
| II. Өстәмә хезмәтләр | | | |
| 38. | Чарада тавыш операторы хезмәтләре | 1 сәгать | 500,00 |
| 39. | Чарада тавыш яңгырашы буенча тавыш режиссеры хезмәтләре | 1 сәгать | 1000,00 |
| 40. | Тавыш яздыру өчен вокалчы хезмәтләре | 1 хезмәт | 1000,00 |
| 41. | Тавыш яздыру өчен диктор хезмәтләре | 1 хезмәт | 1000,00 |
| 42. | Тавышны монтажлау | 1 хезмәт | 1000,00 |
| 43. | Аранжировка ясау (әзерләү) | 1 хезмәт | 4000,00 |
| 44. | Реклама аудио ролигы ясау (җитештерү) (20 сек) | 1 хезмәт | 3000,00 |
| 45. | Реклама аудио ролигы ясау (җитештерү) (15 сек) | 1 хезмәт | 2500,00 |
| 46. | Реклама аудио ролигы ясау (җитештерү) (10 сек) | 1 хезмәт | 2000,00 |
| 47. | «Тере» ВИА берләштерү һәм мастеринг | 1 хезмәт | 5000,00 |
| 48. | «Плюс» фонограммаларын берләштерү һәм мастеринг | 1 хезмәт | 3000,00 |
| 49. | Тере ВИА яздыру | 1 хезмәт | 6000,00 |
| 50. | 1 музыка коралын яздыру | 1 хезмәт | 1000,00 |
| 51. | Вокаль ансамбль тавышын яздыру | 1 хезмәт | 2500,00 |
| 52. | Диктор тавышын язу | 1 хезмәт | 1000,00 |
| 53. | Модульле сәхнәдән файдаланып чара үткәрү | 1 секция/1 көн | 1000,00 |
| 54. | LED-экраннан файдаланып, чараны видео белән алып бару | 1 сәгать. | 1000,00 |
| 55. | Проектордан файдаланып, чараны видео белән алып бару | 1 сәгать | 500,00 |
| 56. | Чараны музыка белән алып бару | 1 сәгать | 1000,00 |
| 57. | Күчмә чараны музыка белән алып бару | 1 сәгать | 2 500,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 58. | Вокаль радио системасыннан файдаланып, артист (вокалчы) тавышын яңгырату | 1 сәгать | 500,00 |
| 59. | Премьер залда чараны музыка белән алып бару | 1 сәгать | 1500,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева